УДК 811.512.145

*И.Б. Бәширова*

# ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ВАРИАНТЛЫЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

На протяжении всей своей истории старотатарский литературный язык функционировал в различных письменных вариантах, которые дифференцириуются на основе употребления арабо-персидских заимствований, слов и словоформ живого разговорного языка и огузско-турецких элементов. В статье анализируется особенности отражения данных вариантов в произведениях старотатарской литературы, созданных в Поволжье в различные эпохи.

**Ключевые слова:** тюркский язык, тюрки, старотатарский язык, живой разговорный язык, письменный литературный язык, арабско-персидские заимствования, огузско-турецкие слова и словоформы, норма и вариативность нормы.

Тормыш-көнкүреш өчен зарур булган эшчәнлек төрләре, әдәби язма текстларда чагылыш тапканнан соң, иҗтимагый фикер (аң) дәрәҗәсендә ныгытыла һәм, дәүләт тарафыннан кирәк дип саналса, аларны алга таба яшәтү дәвам ителә. Яңа вазгыять шартларында барлыкка килгән эшчәнлек төрләрен характерлап язу барышында әдәби телнең кулланылыш өлкәсе тагын да киңәя һәм шул нигездә ул структур яктан да байый (әдәби телдә яңа сүзләр, терминнар файдаланыла башлый һ.б.). Дәверләр буена эзлекле рәвештә үсештә булган иске язулы телләрдә традицион нормалар төрле объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән вариантлары белән бергә кулланылган. Норма һәм норма вариантлылыгы белән бәйле мәсьәләләрне теоретик һәм практик аспектларда тикшерү әдәби телләрнең үсешен күзалларга, шул үсешне яшәтә торган вариантларның табигате һәм вазифасын тулырак ачыкларга мөмкинлек бирә. Алар соңгы елларда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» (2014) һәм «Татар әдәби теле тарихы» (2015) хезмәтләрендә чагылыш тапты. Биредә төп максат – меңъеллар буена кулланылышта булган төрки-татар теленең төрле вариантлары барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау. Әлеге үзенчәлекнең хәзерге әдәби телдә чагылыш табу-тапмау мәсьәләсенә ачыклык кертү бүгенге көндә дә тел белемендә хәл итәсе проблемаларның берсе булып кала бирә.

**Төрки-татар теле – иске язулы телләрнең берсе.** *Төрки* терминының, төрки гаиләдәге кавемнәрнең исем-шәрифе, аларның сөйләмә һәм язма телләренең атамасы булуы М. Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» сүзлегендә тәфсилләп аңлатылуы мәгълүм (466/1072–1074). Бу атамалар хәзерге вакытта да шул ук мәгънәләре белән кулланыла. «Языки мира: тюркские языки» исемле энциклопедик басмада язма традицияләре ерак

гасырлардан килә торган һәм язылу тарихы билгеле булган язма истәлекләргә ия борынгы төрки телләр рәтендә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгыр, үзбәк телләре белән бергә, татар теле дә карала [Языки мира..., с. 358]. Иске язулы телләр, кагыйдә буларак, әдәби нормаларга нигезләнә, ә нормалар традицияләр нигезендә дәвам иттерелә. Язма норма дигәндә, график билгеләр системасы һәм аларның графо-орфографик тәртибе күздә тотыла.

Бүгенге көндә Идел – Чулман буйларында Болгар дәүләте чорыннан сакланып калган рун язулы истәлекләр табылу дәвам итә [Курбатов, б. 13–32]. 922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү белән бергә, гарәп алфавиты гамәлгә куела һәм әлеге графика болгар-татарларда XX йөзнең беренче чирегенә кадәр кулланылышта була. Гарәп язуында Болгар дәүләтендә XIII гасырда угыз-кыпчак нигезле телдә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы иҗат ителә [Хисамов, б. 10]. Поэма 1233 елның 12 маенда тәмамлана. XIII–XIV гасырларда Болгар дәүләтенең Казан төбәгендә гарәп графикасы белән каберташларга штамп-текстлар языла. Болардан алдарак, XII йөздә, Төркестанның мәдәни үзәге саналган Яссы шәһәрендә, кимәк-кыпчак-искел-болгар-татарларның сөйләмә телендәге уртак сүз, сүзформаларга нигезләнеп әдәбиләштерелгән, Әхмәт Ясәви (1166 елда вафат), Сөләйман Бакыргани (1111–1186) һ.б.ның әсәрләрендә чагылыш тапкан, киң катлам төрки кавеменә аңлаешлы телдә язу башлана. Галимнәр фикеренчә, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә дә бу телнең традицияләре дәвам иттерелә [Гайнетдинов, б. 252–253]. Димәк, хәзерге татар әдәби язма теленең мең еллар буена эзлекле рәвештә килә торган тарихы бар, дип әйтә алабыз. Төрки-татар телендә барлык жанр-стильләргә дә караган (матур әдәбият, эш кәгазьләре, фәнни, дини-дидактик, иҗтимагый-публицистик һ.б.) язма әдәбият барлыкка килә. Алар галимнәр тарафыннан барысы да диярлек өйрәнелгән. Әмма бүгенге көндә әдәби тел тарихын тулаем күз алдына китерү өчен, бу истәлекләрне өйрәнү барышында моңарчы кулланылган ысуллар кулай булмаганга, фәнни тикшеренүләрнең методологиясен яңартып, аларны ныклы бер системага нигезләп, язма телнең традициясен, норма һәм норма вариантларының кулланылыш үзенчәлекләрен тәгаенләргә кирәк. Аерым алганда, язма әдәби телне тармакларга бүлеп тикшерә башлаганчы, алдагы хезмәтләрдә чагылыш тапмау сәбәпле, төрки тел һәм иске татар теленең табигатен, вазифасын, әдәби телнең тарихын һәм язма нормаларның үсешен өйрәнгәндә кулланыла торган метод-ысулларны барлау, бу мәсьәләләрнең ничек итеп өйрәнелүен ачыклау соралды. Моның өчен язма телнең Болгар, Алтын Урда чорларында, Казан ханлыгында һәм аннан соңгы дәверләрдә ничек яшәвен, ничек файдаланылуын күз алдына китерү зарур. Нәтиҗәдә, иске татар әдәби теленең (XIII гасыр –

XX гасыр башы) фонетика һәм графика тармакларында язма традициянең ничек баруы, норма һәм аның вариантлары мәсьәләсе анализланып, «Татар әдәби теле тарихы» ның 1 томы дөнья күрде (Казан, 2015). Бүгенге көндә әлеге эш морфология һәм лексика тармаклары өчен алып барыла.

**Язма телнең гомумтөрки чорда ук аристократ-абруйлы (престижный) һәм халыкчан-сөйләмә вариантларга дифференциацияләнүе.** Бу мәсьәлә беренче мәртәбә «Татар әдәби теле тарихы»н язганда калкып чыкты. Әдәби телнең тарихын ныклы бер системага салып тикшергәндә һәр дәвердә язма телнең табигате һәм вазифасының нинди үсеш-үзгәреш кичергәнлеге күренә. XI гасырдан башлап XIX гасыр ахырына кадәр иҗат иткән авторларның барысы да диярлек әсәрләренең төрки телдә язылуына, ягъни гарәп яисә фарсы телендә язылмаганлыгына басым ясап, кат-кат искәртә баралар. Әлеге аерымлану «Котадгу Белек» һәм «Диване хикмәт»ләрдән башлана. Йосыф Хаҗ Баласагунлының төрки дөньяда ислам идеологиясен аңлату һәм тарату максатын күздә тотып язылган беренче мәшһүр әсәрендә (1069), үзеннән-үзе аңлашылганча, гарәп һәм фарсы алынмалары мул кулланыла. Шул ук вакытта анда Орхон язмаларыннан килә торган югары стильдәге региональ төрки архаик сүз һәм сүзформалары да файдаланыла. Галимнәр фикеренчә, бу әсәр Караханилар империясендә (840–1212) ханнар ханы Кара Боғрахан хөкем сөргән вакыттагы аристократ-абруйлы язма әдәби тел белән иҗат ителгән [Кононов, с. 502; Благова, с. 99–100]. Әхмәд Ясәвинең (1091–1166) «Диван-е хикмәт»ләрендә исә «...аять, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ / Мәгънәсенә йиткәнләр йиргә куяр бүркене», – дип, төрки телдә дә гыйлемле булу мөмкинегә турында белдерелә [Татар әдәбияты.., 2014, б. 139]. Нәтиҗәдә алынмаларны куллану билгеле бер дәрәҗәдә азая.

Төрки тел дигәндә, киң далаларда таралып яшәгән төркиләрнең диалектларындагы аларның күбесе өчен уртак һәм әдәбиләштерелгән сөйләмә сүз һәм сүзформаларына нигезләнгән халыкчан язма әдәби тел истә тотыла. «Татар әдәби теле тарихы» хезмәтен язу барышында әдәби истәлекләрнең дәверләр дәвамында янәшә кулланылып килгән, берсе икенчесенә бәйле булган ике төрле төрки телдә язылганлыгы мәгълүм булды [Татар әдәби..., 2015].

Аристрокат-абруйлы классик иске татар телендә, ягъни сөйләмә-диалекталь сүз һәм сүзформаларына караганда, гарәп-фарсы алынмалары күбрәк кулланылган телдә язылган әсәрләр дигәндә, XIII гасырда Болгар дәүләтендә тудырылган «Кыйссаи Йосыф», XIV гасырда Алтын Урдада иҗат ителгән дини вә дөньяви әдәбият, XV–XVI гасыр уртасына кадәр Казан ханлыгында язылган Өмми Камал шигырьләре, Максудиның (Мөхәммәд Әмин) «Могҗизнамә» һәм «Мансур Хәлләҗ кыйссасы» әсәрләре, Мөхәммәдъяр поэмалары,

Кол Шәриф әсәрләре, Әднаш Хафизның «Сираҗел колүб» әсәре күз алдында тотыла. XVI гасыр ахыры – XVII гасырда проза жанры үсеш алу сәбәпле, бу мәсьәлә шактый катлаулана. Тәгаен билгеле иҗтимагый-сәяси вакыйганы «әкиятләштереп» язылган «Җәмигыт-тәварих» [Татар әдәбияты..., 2014, б. 205] һәм «...халык хыялы күзаллаган тарихи хәл» буларак язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә» («Дастаннар китабы») [Татар әдәбияты..., 2014, б. 207] әсәрләре телендә халык авыз иҗатына хас җанлы сөйләмә формаларның чагылышы табигый булып кабул ителә. Фарсы телендә иҗат ителгән әсәрен төркиләштереп язган Суфи Аллаһиярның (1616–1713) «Сөбател-гаҗизин» теле, әлбәттә, абруйлылыгын саклап, Мәүлә Колыйның халыкчан сөйләмә телне әдәбиләштерелеп язылган «Хикмәтләр»е теленнән аерыла. XVIII гасыр урталарыннан башлап XIX гасырның беренче яртысына кадәр дәвам иткән дәвердә Батыршаның (Абдулла Алиев) (1710–1762) «Гарызнамә»се (1756), Т. Ялчыголның (1768–1838) «Рисаләи Газизә: шәрхе «Сөбәтел-гаҗизин» (1796/1847/1850) әсәре, Г. Утыз Имәни (1754–1834), Ә. Каргалый (1782–1833), Һ. Салихов (1794–1867), Ш. Зәки (1822–1865) һәм Г. Чокрыйның (1826–1889) бераз соңрак язылган тезмә әсәрләренең гарәп-фарсы алынмалары һәм гомумтөрки архаик формалар мул кулланылган аристократ төркидә иҗат ителүе мәгълүм.

Шул ук вакытларда абруйлы классик иске татар телендәге әсәрләр белән рәттән халыкчан юнәлештәге классик иске татар телендә, ягъни җанлы сөйләмә-диалекталь сүз, сүзформаларының гарәп вә фарсы алынмаларына караганда күбрәк кулланылып язылган әсәрләр параллель бара. Биредә XV гасыр – XVI гасыр уртасында яшәгән Хәсән Кайгы Дусмәмбәт, Казтуган һ.б. шагыйрь-җыраулар иҗатын, XVII гасырда иҗат иткән Мәүлә Колый «Хикмәтләр»ен, билгеле бер дәрәҗәдә халык авыз иҗаты үзенчәлекләрен файдаланып язылган «Җәмигыт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» кебек тарихи истәлекләрне искә алу кирәк. XVIII гасыр дәвамында иҗат ителгән илаһи бәетләр, авторлар үзләре искәртә барганча, Болгар-Казан шивәсенең җанлы сөйләмә һәм халык авыз иҗаты үзенчәлекләре белән баетылган халыкчан иске татар телендә тудырылганнар. Бу юнәлеш XIX гасырда Баһавиның «Бүз егет китабы» (1842) һәм Г. Кандалый (1797–1860), Әхмәт Уразаев-Кормаши (1855–1883), М. Акмулла (1831–1895), Яков Емельянов (1848–1893) шигырьләрендә дәвам итә. Бу авторларның әсәрләрен фәнни өйрәнү күрсәткәнчә, традиция булып параллель килә торган ике варианттагы язма телдә иҗтимагый тормыш таләпләре яисә иҗтимагый фикер үсеше, әдәби-мәдәни багланышлар тәэсирендә әдәби телнең һәр чорында билгеле бер яңарышның барлыкка килүе күзәтелә.

**Әдәби телдә язма норма һәм вариантларның яңарып дәвам ителеше.** Тикшерүләрдән күренгәнчә, һәр чорда әдәби тел-

нең кулланылышында, гасырлардан гасырларга күчеп килгән ике төрле традициясе-нигезе сакланган хәлдә, үзенә хас булган яңалыклар барлыкка килә. Һәр дәвернең иҗтимагый-сәяси шартларына, әдәби телнең әсәр язылган төбәктә яшәүчеләрнең җанлы сөйләмә һәм халык авыз иҗаты әсәрләре теле үзенчәлекләре белән бәйләнешенә, шул чорда яшәгән авторларның белеме, нинди тема күтәрүләре, аларның әдәби телнең кайсы жанр-стилендә, кайсы укучыны күздә тотып иҗат итүләренә, гомумән максатлары нинди булуга һ.б. шартларга бәйләнеш-мөнәсәбәттә әдәби телдә барлыкка килгән яңалыклар язма норманың дәвам ителешенә дә, вариантларның табигатенә һәм вазифасына да, хәтта төрки тел дигән төшенчәнең нинди мәгънә белән кулланылышына да тәэсир итәләр. Әлеге катлаулы мәсьәләләр әдәби тел тарихын җентекле анализлау нәтиҗәсендә генә ачыла баралар.

Югарыда китерелгән мисалларга бәйле рәвештә, иҗтимагый-сәяси шартлар дигәндә, иң беренче чиратта, төрки-татарларның, XII–XVI гасыр уртасына кадәр дәүләтле халык булып яшәп тә, 1552 елдан чит дәүләттә яшәргә мәҗбүр ителүе истә тотыла. Бу вакытка кадәр язылган әдәбиятта әдәп-әхлак, Аллаһыдан курку, гөнаһлардан саклану кебек мәсьәләләр яктыртыла. XVI гасырның икенче яртысыннан башлап иманны саклау төп проблема булып күтәрелә, ул риваятьләргә нигезләнеп аңлатыла. XVII йөздә белемсезлек, мәгърифәтсезлекнең имансызлыкка илтүе мәсьәләләре яктыртыла башлый, «онытылып юкка чыгу чигенә җиткән әсәрләр» кабат җанландырыла» [Татар әдәбияты ..., 2014, б. 207]. Иман өчен җаваплылык тулысынча шәхеснең үзенә йөкләнә, алгы планга кешенең иҗтимагый активлыгы, үз сүзендә нык тору зарурлыгы кебек мәсьәләләр чыга. XVIII гасыр урталарына кадәр, ягъни мәдрәсәләр торгызылып, милли мәгариф аякка басканчы, әдәби истәлекләрнең барысы да халыкның хәтерен, иманын, киләчәккә булган ышанычын саклау максаты белән языла, аның шәһәравыллары, җир-сулары, урманкырлары, укымышлы кешеләренең исем-шәрифләре, аларның каберләре кайда булулары тәфсилләнә, ислам дине кануннары буенча яшәгәндә генә кеше булып калырга мөмкинлек аңга сеңдерелә. Бу чорда бер үк әсәрләрдә гарәп-фарсы алынмалары һәм төрки-татар сүз һәм сүзформалары, нигездә, бергә файдаланыла. Прозада синкретизм саклана: бер үк әсәрдә хәзерге филологиядә хосусый сөйләм тибы булып аерып чыгарылган төрле стильләрнең берьюлы берничәсенә (әдәби, фәнни, публицистик) хас үзенчәлекләрнең бергә үрелеп китүе күренә. Галимнәр билдергәнчә, моның ачык мисалы булып Батыршаның «Гарызнамә» трактаты санала [Гайнетдинов, б. 96].

Шуның белән бергә җәмгыятьттә бара торган вакыйгаларның язма текстларда турыдантуры теркәлә баруы әдәби телдә жанр-стильләрнең аерылуын көчәйтә. Бу хәл Пугачев хәрәкәте

белән бәйле рәсми эш кәгазьләрендә ачык чагыла (1773–1775), иске татар телендә өндәмә, манифест, указ, устав, билет һ.б. рус теле терминнары файдаланылып язылa башлый [Фасеев, с. 62].

Төрки тел дигән төшенчә, XVI гасыр ахырында Әднаш Хафизның «Сираҗел колүб» әсәрендә гарәби һәм фарсига каршы куелып, татар халкының яшәгән вазгыятькә бәйле рәвештә, заманалар ахыры җитү сәбәпле (Казан ханлыгының Мәскәү дәүләте тарафыннан басып алынуы күздә тотыла), исән калганнарның теле мәгънәсендә кулланыла башлый [Татар әдәби..., 2015, б. 146]. Алга таба ул Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәрендә «кәндү-үз телемез», ягъни болгар-татар телендә сөйләшүчеләрнең телләре дигән мәгънәдә дәвам ителә. Шул ук вакытта Г. Утыз-Имәнинең, гыйлем белән генә гамәл кылу дөрес була, дигән фикере үстерелә. Язма телнең күпсанлы гарәп-фарсы алынмалары белән туендырылуы Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б. иҗатларында дәвам итеlә. Алар үзләренең әсәрләрен аңлы рәвештә авторның фикер агышын аңлый торган укымышлы-гыйлемле кешегә багышлап язалар. Укучыга карата мөнәсәбәт иҗтимагый-функциональ яңгыраш ала. Болгар-Казан шивәсе дип атала торган төрки телне куллануда иҗтимагый-социаль аерымлану хасил була. Шулай итеп, гасырларны узып килгән төрки телнең аристократ-абруйлы һәм сөйләмә-халыкчан вариантларының кулланылуы, һәр дәвердә төрле иҗтимагый вакыйгаларга яраклашу максатыннан билгеле бер яңарышлар алып дәвам итә.

XIX гасырның урталарында татар халкының бөек мәгърифәтчесе К. Насыйри (1825–1902) эшчәнлегенең башында ук сөйләү теле белән язу теленең хосусый үзенчәлекләре булуына игътибар итә. (Бу мәсьәләнең асылы әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә аңлатылмаган.) Әдәби әсәрләрен аңлы рәвештә халыкчан тел белән, фәнни хезмәтләрен, «һәрбер фәннең үзенә мәгълүм истыйляхы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр...» дип, һәр фән тармагының үзенә яраклы булган терминнарын кулланып яза.

Бу чорда татар язма теле функциональ-стилистик яктан аерымланып тикшерелү мөмкинлеге ала. С. Кукляшев тарафыннан тәкъдим ителгән, язма татар телен гади (простой), эш (деловой), гыйльми (ученый) төрләргә бүлеп карарга мөмкин, дигән теоретик фараз [Кукляшев, 1859] К. Насыйри иҗаты белән гамәли яктан раслана. Төрле авторларның төрле әсәрләрендә параллель килә торган ике вариантлы иске татар теле XIX гасырның ахырларына таба Г. Кандалый (1797–1860), Г. Тукай (1886–1913) кебек авторларның төрле әсәрләрендә уңышлы файдаланыла.

**Иске татар теленең угыз-төрек варианты.** XVI гасырдан Россия хакимиятенә төрки телле халыклар белән аралашу өчен тылмачлар, писерләр, илчеләр кирәк була башлый. Көнчыгыш илләре, шул исәптән Урта Азия илләре, Кырым белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда

иске татар теле XVI гасырдан XIX гасыр башларына кадәр икенче функциональ дәүләт теле булып файдаланыла. XVIII гасыр ахырларына таба сәнәгать, икътисад өлкәсендәге хәрәкәт халыкларның иҗтимагый аңы, мәдәнияте, мәгарифе үсешенә тәэсир итә, мәдрәсәләр ачыла, алар өчен дәреслек булырдай әсәрләр языла, халыкның хәтерен, динениманын, кешелеген саклау фикере сәнгатьчә тасвирланып бирелә. Һәм болар барысы да, авторлар үзләре белдергәнчә, Болгар-Казан төркисендә тормышка ашырыла. Бу чорда язылган «Сәяхәтнамәләр»дә дә халыкчан сөйләмә тел өстенлек итә.

Төркиләрнең мәдәни тормышында көчле мәдәни яңарыш буларак 1883 елда Кырымда «Тәрҗеман» газетасы басыла башлый. Аның финанс ягын тәэмин итүгә Идел буе татарлары да шактый өлеш кертә. Газетаны редакцияләү һәм чыгару эшендә Зөһрә Акчурина, Муса Акъегетзадә кебек татар укымышлылары актив катнаша. Нашир Исмәгыйль Гаспралы бу җәридәне, барча төрки халыклар укый һәм файдалана алсыннар, дигән изге ният белән, барысына да аңлаешлы булган «урта лисан» – бер шивәдә чыгарырга тырыша. Төрки кавемнең күпчелеген угыз телләре тәшкил иткәнгә күрә, «урта лисан» дигәндә традицион абруйлы төркинең угызчылык белән баетылган варианты – язма аралашу теле барлыкка килә. Г. Ибраһимов раславынча, «Тәрҗеман» бик тиз арада Идел буе мәдрәсәләрендә һәр саны зарыгып көтеп алынган үз газетага әйләнеп китә. Татар телендә газета бастырырга рөхсәт алыну белән, «Нур» газетасында «Әдәби телемез нә делдер?» дип башланган бәхәстә бу күренеш, иске татар теле дигән төшенчәгә каршы куелып, төрек-госманлы теле дип атала («Нур», 1905, № 4 һ.б.). М. Акъегетзадәнең (1864–1923) татар әдәбиятында реалистик прозаның беренче үрнәге дип санала торган «Хисамеддин менла» әсәре (1886) менә шушы телгә якын булган төрки-татар телендә иҗат ителә. Автор үзенең милли романында «Тәрҗеман»ны «Русия исламларының сәламәтене вә хөсне мәгыйшәтене мөхафәзә идән (*саклый торган*) җәридә» дип атый [Акъегет, б. 4]. М. Акъегетзадә «урта лисан»ны файдалана: бер үк төшенчә *авыл, карья, көй* дип өч төрле тел сүзләре белән бирелә. Шул ук вакытта, ул үз туган төбәгендәге мишәр диалектына хас булган *кырмалау, бакты, ашагы* һ.б. сүзләрне дә куллана. Язма телдәге әлеге яңалыкка төрлечә мөнәсәбәт белдерелә. Г. Баттал Таймас (1883–1969) «melez dıl» (катнаш тел) барлыкка килде дип саный. Бу билгеләмәне Адилә Айда (1912–1992) «Садри Максуди Арсал» дигән хезмәтендә, М. Акъегет әсәре Казан телендә язылмаган, аның әдәбият тарихында кыйммәте юк, С. Максудиның «Мәгыйшәт» хикәясе генә саф Казан телендәге беренче әсәр, дигән фикерен раслау өчен китерә [Айда, б. 23–25].

XIX йөз ахырына таба татар халкының танылган мәгърифәтчеләре, төркиләрнең күпчелеге укысын дигән максатны күздә

тотып, кайбер әсәрләрен, «урта лисан» белән иҗат итәргә кирәк дип санаулар. З. Бигиевнең (1870–1902) тулаем төрки дөнья укып аңласын дигән максат белән язылган «Мавәраэннәһердә сәяхәт» юлъязмасы (1902), татар укучысына тәкъдим ителә торган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» (1887) һәм «Гөнаһе кәбаир» (1890) әсәрләренең теленнән шактый аерылып, угыз-төрки сүз һәм сүзформалары белән баетылып бирелә.

Күренекле әдип һәм мәгърифәтче-педагог, танылган тәрҗемәче һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм мөхәррир Ф. Кәриминең (1870–1937) татар укучысы укысын дип язылган «Салих бабайның өйләнүе» (1897, 1901), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1899) һ.б. хикәяләре язма телнең җанлы-сөйләмә халыкчан варианты белән иҗат ителә. «Вакыт» газетасында басылган күпчелек мәкаләләренең теле дә асылда әлеге юнәлештә бара: «Рус милләтчелеге» («Вакыт», 1910, 4 февраль), «Кем иде Шакир әфәнде?» («Вакыт», 1912, 25 март) һ.б. Ф. Кәриминең төрле фәннәргә караган тарихи, дини әсәрләрендә истыйлах-терминнар күп кулланылганга, «Мәрхүм Гыйльман ахунд» рисаләсендә рәттән диярлек гарәп-фарсы алынмалары файдаланылганга иске татар теленең классик-абруйлы варианты белән файдалану барлыкка килә. Авторның барлык төркиләр дә укысын дип язылган «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902) һәм «Кырымга сәяхәт»е (1904), аңлашылганча, «Тәрҗеман» газетасында чагылыш тапкан «урта лисан» белән языла.

Мөселман дөньясында мәшһүр дин белгече, философ, мәгърифәтче-педагог, тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе, әдип вә публицист Р. Фәхретдиннең (1858–1936) иҗатында да, әдәби телнең өч тармагын куллану дәвам ителә. Татар халкының «ак өстендә кара таныган» күпчелек укучылары өчен «ачык ана телемездә» дигән искәрмә белән «Тәрбияле ана» (1898), «Тәрбияле бала» (1898), «Тәрбияле хатын» (1899) һ.б. гыйльме әхлак һәм көндәлек тормышны алып баруда кирәкле тәртип-низам турындагы дөньяви-дидактик әсәрләре халыкның җанлы сөйләменә хас булган сүз һәм сүзформалары файдаланылып, классик иске татар теленең халыкчан варианты белән языла. «Сәлимә яки гыйффәт» (1898), «Әсма яки гамәл вә җәза» (1903) кебек сәнгатьле чәчмә әсәрләре дә, шушы ук юнәлешкә нигезләнә. Р. Фәхретдин, танылган галим, теолог Ш. Мәрҗани (1818–1889) тарафыннан гарәп телендә язылган биобиблиографик хезмәтне дәвам итеп, төрки-татар телендә ике җилд, 14 җөзьәдә «Асәр»ен төзи (1900–1908). Әлеге хезмәтен автор Диния нәзарәтенә казый итеп сайлангач яза башлый, шуның белән бергә ул архивтагы күпсанлы кулъязмаларны да тәртипкә китерә. Бу язмаларның күбесе имам вә мөдәррисләрнең эшләренә һәм тормышларына караган чыганаклар, ягъни эшчәнлекләре турыдан-туры гарәп, фарсы, төрек телләре белән бәйле шәхесләр хакында була. Әле-

ге хезмәтнең жанры, үзенчәлекле материалы традицион классик иске татар теленең гарәп-фарсы алынмалары мул кулланыла торган вариантында гына язылa алган. Әдипнең дини-рухи эчтәлекле «Коръан вәтәбәгать» (1900), «Мөхәммәд галәйһиәссәлам» (1908), «Җәвамигуль-Кәлим шәрхе» (1911) хезмәтләренең теле дә шушы юнәлештә бара. Р. Фәхретдиннең барлык төрки телле халык укып аңласын дип язылган фәнни хезмәтләре һәм «Шура» журналында (1909–1918) эзлекле рәвештә басылып килә торган мәкаләләренең күбесе «Тәрҗеман» теленә якын булган «урта лисан»да языла. В. Бартольд «Шура» журналының телен «госманлыча катышкан Казан татарлары әдәби теле» дип белдерә [Мәрдәнов, б. 31–32]. Димәк, иске татар әдәби телендә урын алган бу вариантның хосусый яшәвенә махсус рәвештә игътибар ителә. Поэзия әсәрләрендә угызлашкан вариантның гүзәл үрнәге татар халкының тулаем төрки дөньяда дан алган, даһи шәхесе Г. Тукай иҗатында дәвам ителә.

Иҗтимагый тормышта бара торган вакыйгалар әдәби телнең үсеш-үзгәрешенә тәэсир иткән кебек, әсәрләрнең теле өйрәнелеп языла торган хезмәтләргә дә үзенчә йогынты ясый. 1930 еллардан соң билгеле бер эзлеклелектә иске татар теленең һәр өч варианты да юкка чыгарыла бара. Әлеге йогынтының ничек баруын күзәтү барышында, кызганыч ки, әдәби телнең угызлашкан вариантының вазифасын аңламау һәм аны ярсып инкарь итү хронологик яктан беренче булып тора. Бу мәсьәлә Г. Тукайның башлангыч чор иҗатына тәнкыйть мәкаләләре язган күренекле әдип Ф. Әмирхан (1887–1926) тарафыннан мәйданга куела. Алга таба әлеге мәсьәлә панисламизм, пантюркизм дигән төшенчәләр белән бергә кулланылып, сәясәткә бәйләп күтәрелә, аннан соң, әдәби язма тел сөйләмә телгә тәңгәл булырга тиеш, дигән тәгълимат нигезендә, филологик планда кире кагыла, шул сәбәпле «урта лисан»да язылган әсәрләрнең теленә фәнни объектив бәя бирелмичә кала.

Гасырлар буена, билгеле бер үзгәрешләр белән, беренчедән, гарәп-фарсы алынмалары мул кулланылып һәм, икенчедән, гомумтөрки уртак сөйләмә сүзләр әдәбиләштерелеп язылган, аристократ-абруйлы һәм сөйләмә-халыкчан вариантлары белән ике параллель нигездә барган иске татар теле XIX гасырның икенче яртысыннан, аерым әдипләр күпчелек төркиләр аңласын дигән максатны күздә тотып яза башлау сәбәпле, өч вариантлы булып файдаланыла башлый. Угызлашкан өченче вариантка караган әсәрләр барлык төркиләр укысын дигән максат белән басыла башлаган «Тәрҗеман» газетасының «урта лисан»ына якын телдә язылалар, нәтиҗәдә язма әдәби телдә аралашу тагын да киңәя. Алга таба ул татар зыялылары тарафыннан теоретик планда көчле тәнкыйть утына тотылса да, гамәли яктан билгеле бер үзгәрешләр белән дәвам ителә.

**Әдәбият**

*Айда А.* Садри Максуди Арсал. Анкара: Культур Баканлыгы, 1991. 290 б.

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Благова Г.Ф.* О методике изучения морфологии средневековых тюркских поэтических текстов // Вопросы языкознания, 1977. № 3. С. 86–100.

*Гайнетдинов М.В.* Литература XVIII века // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). Казань: Фэн, 1999. 240 с.

*Кашгари М.* Диван Лугат ат-Турк / перевод, предисловие и комментарии З.-А.М. Ауэзовой. Индексы составлены Р. Эрмерсом. Алматы: Дайк-Пресс, 2005. 1288 с.

*Кононов А.Н.* Поэма Юсуфа Баласагунского «Благодатное знание» // Юсуф Баласагунский. Благодатное знание. М.: Наука, 1983. С. 495–517.

*Кукляшев С.* Татарская хрестоматия. Казань: Тип. ун-та, 1859. 107 с.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Татар. кит. нәшр., 1999. 139 б.

*Мәрданов Р.* «Шура» журналы (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан: Рухият, 2001. 152 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. 415 б.; 2 т.: XV–XVIII гасырлар. 471 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 696 б.

*Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII века. Казань, 1982. 171 с.

*Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII–XV йөзләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 208 б.

Языки мира: Тюркские языки. Бишкек: Кыргызстан, 1997. 543 с.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***

*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*